| Бетергеч | данә | 2 |
| Гуаш буявы | упаковка | 2 |

**6 нчы таблица**

**Гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатта яшәүче тәрбияләнүчеләрне уеннар һәм уенчыклар белән тәэмин итү нормалары**

| Ял итү чараларының, уеннарның һәм ял вакытын оештыруның аталышы | Норманы үлчәү бердәмлеге | Елына бер тәрбияләнүчегә норма |
|---|---|---|

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| Кинотеатрга йөрү | бару саны | 6 |
| Театрга йөрү | бару саны | 2 |
| Циркка йөрү | бару саны | 1 |
| Электрон уен | данә | 0,1 |
| Ледянки | данә | 0,3 |
| Тимераяк | данә | 0,3 |
| Чаңгы | данә | 0,1 |
| Китаплар | данә | 4 |

2.8. Тәрбияләнүчеләрне кием-салым, аяк киеме, йомшак инвентарь, шәхси гигиена һәм хуҗалык җиһазлары, уку-язу әсбаплары, уен һәм уенчыклар белән тәэмин итү чыгымнары түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$R_v odes = \frac{1}{2} \times \left(\sum_{i_1=1}^{n_1} N^g_{i_{1_{vcl}}} \times C_{i_{1cl}} + \sum_{i_2=1}^{n_2} N^b_{i_{2_{vcl}}} \times C_{i_{2cl}}\right) + \frac{1}{2} \times$$

$$\times \left(\sum_{i_3=1}^{n_3} N_{i_{3_{vgig}}} \times C_{i_{3gig}} + \sum_{i_4=1}^{n_4} N_{i_{4_{vgig}}} \times C_{i_{4_{vgig}}}\right) + \sum_{i_5=1}^{n_5} N_{i_{5inv}} \times$$

$$\times C_{i_{5inv}} + \sum_{i_6=1}^{n_6} N_{i_{6_{vcan}}} \times C_{i_{6can}} + \sum_{i_7=1}^{n_7} N_{i_{7_{vtoy}}} \times C_{i_{7toy}},$$

биредә:

$R_v odes$ - тәрбияләнүчеләрне кием-салым, аяк киеме, йомшак инвентарь, шәхси гигиена һәм хуҗалык инвентаре предметлары, уку--язу әсбаплары, уен һәм уенчыклар белән тәэмин итү чыгымнары;

$N^g_{i_{1_{vcl}}}$, $N^b_{i_{2_{vcl}}}$, $N_{i_{3_{vgig}}}$, $N_{i_{4_{vgig}}}$, $N_{i_{5inv}}$, $N_{i_{6_{vcan}}}$, $N_{i_{7_{vtoy}}}$ -2.7 пункты нигезендә кабул ителә торган кызларны кием һәм аяк киеме, малайларны кием һәм аяк киеме, кызларның шәхси гигиена әйберләре һәм хуҗалык инвентары, малайларның шәхси гигиена әйберләре һәм хуҗалык инвентары, йомшак инвентарь, уку-язу кирәк-яраклары, уеннар һәм уенчыклар белән тәэмин итү нормалары;

$C_{i_{1cl}}$, $C_{i_{2cl}}$, $C_{i_{3gig}}$, $C_{i_{4_{vgig}}}$, $C_{i_{5inv}}$, $C_{i_{6can}}$, - $C_{i_{7toy}}$ -2.7 пункты нигезендә кабул ителә торган кызларны кием һәм аяк киеме, малайларны кием һәм аяк киеме, кызларның шәхси гигиена әйберләре һәм хуҗалык инвентары, малайларның шәхси гигиена әйберләре һәм хуҗалык инвентары, йомшак инвентарь, уку-язу кирәк-яраклары, уеннар һәм уенчыклар бәясе;

$n_1, n_2, n_3, n_4, n_5, n_6, n_7$ –2.7 пункты нигезендә кабул ителә торган кызларны кием һәм аяк киеме, малайларны кием һәм аяк киеме, кызларның шәхси гигиена әйберләре һәм хуҗалык инвентары, малайларның шәхси гигиена әйберләре һәм хуҗалык инвентары, йомшак инвентарь, уку-язу кирәк-яраклары, уеннар һәм уенчыклар белән тәрбияләнүчеләрне тәэмин итү билгеләнгән нормалары исемлегендә товарлар саны;

$i_1, i_2, i_3, i_4, i_5, i_6, i_7$ –2.7 пункты нигезендә кабул ителә торган кызларны кием һәм аяк киеме, малайларны кием һәм аяк киеме, кызларның шәхси гигиена

әйберләре һәм хуҗалык инвентары, малайларның шәхси гигиена әйберләре һәм хуҗалык инвентары, йомшак инвентарь, уку-язу кирәк-яраклары, уеннар һәм уенчыклар белән тәрбияләнүчеләрне тәэмин итү билгеләнгән нормалары исемлегендә товарлар товар исеме.

2.9. Туклануны оештыру чыгымнары, расланган нормативларга һәм тукылануны оештыру буенча методик киңәшләргә ярашлы рәвештә, азык-төлек өчен түләүгә агымдагы чыгымнарны һәм азык-төлек сатып алу чыгымнарын үз эченә ала.

2.10. Тукылануны оештыруның расланган нормативлары буенча тукылануны оештыру чыгымнары түбәндәгеләр нигезендә билгеләнә:

тәрбияләнүчеләрне тукландыру хезмәте күрсәтүнең бәясе;

азык-төлек блогы хезмәткәрләренең хезмәт хакы ставкаларының һәм административ-идарәче персоналның хезмәт хакы ставкаларының норматив нисбәте;

7 нче таблицада каралганча кабул ителә торган тәрбияләнүчеләрне тукландыру нормасы;

планнан алдагы елның 1 сентябренә булган торыш буенча, чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджетын формалаштырганда кулланыла торган индекс-дефляторларны исәпкә алып, азык-төлек товарларының уртача базар бәясе.

**7 нче таблица**

**Гомуми белем бирү оешмалары каршында интернатларда яшәүче тәрбияләнүчеләрне тукландыру нормалары**

| Азык-төлек продуктларының исеме | Үлчәү берәмлеге | Көненә бер тәрбияләнүчегә норма* |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Арыш ипие | граммнарда | 150 |
| Бодай ипие | граммнарда | 250 |
| Бодай оны | граммнарда | 40 |
| Бәрәңге оны | граммнарда | 4 |
| Ярма, кузаклылар, макарон | граммнарда | 75 |
| Бәрәңге | граммнарда | 400 |
| Яшелчә һәм яшел үләннәр | граммнарда | 475 |
| Яңа җыелган җиләк-җимеш | граммнарда | 300 |
| Соклар | граммнарда | 200 |
| Коры җиләк-җимеш | граммнарда | 20 |
| Шикәр | граммнарда | 70 |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| Кондитер эшләнмәләре | граммнарда | 30 |
| Кофе (кофе эчемлеге) | граммнарда | 2 |
| Какао | граммнарда | 2 |
| Чәй | граммнарда | 2 |
| Ит | граммнарда | 110 |
| Кош ите | граммнарда | 50 |
| Балык (сельдь) | граммнарда | 110 |
| Казылык ризыклары | граммнарда | 25 |
| Сөт, әче сөт ашамлыклары | граммнарда | 500 |
| Эремчек | граммнарда | 70 |
| Каймак | граммнарда | 11 |
| Сыр | граммнарда | 12 |
| Атланмай | граммнарда | 51 |
| Үсемлек мае | граммнарда | 19 |
| Йомырка | данә | 1 |
| Тәмләткечләр | граммнарда | 2 |
| Тоз | граммнарда | 8 |
| Чүпрә | граммнарда | 2 |
| * - норма интернатта яшәмәгән , «кадет мәктәбе» дип аталучы махсус исемле гомум белем бирү оешмаларында тәрбияләнүчеләргә кагыла. | | |

2.11. Туклануны оештыру чыгымнары түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$R_v pit = FOT_{vpit} + 210 \times \sum_{i8=1}^{n=8} N_{i8_{pit}} \times C_{i8_{pit}},$$

биредә:

$R_v pit$ - расланган нормалар нигезендә туклануны оештыруга чыгымнар;

$FOT_{vpit}$ - азык-төлек блогы хезмәткәрләренең һәм административ-идарәче персоналның хезмәт хакы фондына исәпләүләр белән азык-төлек блогы хезмәткәрләренең һәм административ-идарәче персоналның хезмәт хакы фонды;

210- елына уку көннәре саны;

$N_{i8_{pit}}$ - 2.10 пункты нигезендә кабул ителә торган тәрбияләнүчеләрне

тукландыру нормалары;

$C_{i8_{pit}}$ - 2.10 пункты нигезендә кабул ителә торган тәрбияләнүчеләрне тукландыруның продуктлары исемлегенә кергән азык-төлек товарларының бәясе;

$n_8$ - 2.10 пункты нигезендә кабул ителә торган тәрбияләнүчеләрне тукландыруның билгеләнгән нормалары исемлегендә азык-төлек товарлары саны;

$i_8$ - 2.10 пункты нигезендә кабул ителә торган тәрбияләнүчеләрне тукландыруның билгеләнгән нормалары исемлегендә азык-төлек товарының исеме.

2.12 Тәрбияләнүчеләрне тукландыру буенча хезмәтләрнең стандарт бәясен исәпләү түбәндәге күрсәткечләрдән чыгып гамәлгә ашырыла:

бер тәрбияләнүчегә азык-төлек блогы төп хезмәткәрләренең ставкалар саны - 0,02;

бер тәрбияләнүчегә азык-төлек блогы ярдәмче хезмәткәрләренең ставкалары саны - 0,01;

азык-төлек блогының төп хезмәткәрләре эш хакы ставкасы алтынчы квалификация разряды буенча тарифлаштырылган, эшчеләрнең гомумтармак һөнәрләре буенча һөнәри квалификация төркемендәге «Эшчеләрнең икенче дәрәҗәдәге гомумтармак һөнәрләре» һөнәри квалификация төркеменең икенче квалификация дәрәҗәсенә керә торган эшчеләр һөнәрләренә туры килә;

азык-төлек блогының ярдәмче хезмәткәрләре эш хакы ставкасы икенче квалификация разряды буенча тарифлаштырылган, эшчеләрнең гомумтармак һөнәрләре буенча һөнәри квалификация төркемендәге «Эшчеләрнең беренче дәрәҗәдәге гомумтармак һөнәрләре» һөнәри квалификация төркеменең беренче квалификация дәрәҗәсенә керә торган эшчеләр һөнәрләренә туры килә

2.13. Административ-идарәче персоналның хезмәт өчен түләү чыгымнары өлеше гомуми белем бирү оешмасының азык-төлек блогы хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү фондыннан 12 процент күләмендә билгеләнә.

2.14. Азык-төлек блогы һәм административ-идарәче персонал хезмәткәрләренең хезмәт хакы фондына исәпләүләр белән азык-төлек блогы һәм административ-идарәче персонал хезмәткәрләренең хезмәт хакы фонды түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$FOT_{v_{pit}} = FOT_{v_{пищ_{осн}}} + FOT_{v_{пищ_{ауп}}},$$

биредә:

$FOT_{v_{пищ_{осн}}}$ - азык-төлек блогы хезмәткәрләренең хезмәт хакы фондына исәпләүләр белән азык-төлек блогы хезмәткәрләренең хезмәт хакы фонды;

$FOT_{v_{пищ_{ауп}}}$ - 2.13 пункты нигезендә кабул ителә торган административ-идарә һәм уку-укыту ярдәмче персоналының хезмәт хакы фонды һәм административ-идарә һәм уку-укыту ярдәмче персоналының хезмәт хакы фондына исәпләүләр;

азык-төлек блогы хезмәткәрләренең хезмәт хакы фондына исәпләүләр белән азык-төлек блогы хезмәткәрләренең хезмәт хакы фонды түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$FOT_{у_{пищ_{осн}}} = (n_{пищ_{осн}} \times b_{пищ_{осн}} + n_{пищ_{всп}} \times b_{пищ_{всп}}) \times e \times 12,$$

биредә:

$n_{пищ_{осн}}$ - 2.12 пункты нигезендә кабул ителә торган азык-төлек блогы төп хезмәткәрләренең ставкалары саны;

$b_{пищ_{осн}}$ - 2.12 пункты нигезендә кабул ителә торган азык-төлек блогы төп хезмәткәрләренең хезмәт хакын түләүгә чыгымнар;

$n_{пищ_{всп}}$ - 2.12 пункты нигезендә кабул ителә торган азык-төлек блогы ярдәмче хезмәткәрләре ставкалары саны;

$b_{пищ_{всп}}$ - 2.12 пункты нигезендә кабул ителә торган азык-төлек блогы ярдәмче хезмәткәрләренә хезмәт хакын түләүгә чыгымнар;

$e$ - законнар нигезендә иминият кертемнәре күләме;

12 - елга айлар саны.

2.15. Тәрбияләнүчеләргә хуҗалык-көнкүреш хезмәт күрсәтүне оештыру чыгымнары хезмәт хакы өчен түләүгә агымдагы чыгымнарны һәм хуҗалык-көнкүреш хезмәтләре буенча хезмәт күрсәтүләрне сатып алу чыгымнарын үз эченә ала.

2.16. Расланган нормативлар нигезендә тәрбияләнүчеләргә хуҗалык-көнкүреш хезмәте күрсәтүне оештыру чыгымнары түбәндәгеләр нигезендә билгеләнә:

тәрбияләнүчеләргә хуҗалык-көнкүреш хезмәте күрсәтүнең бәясе;

тәрбияләнүчеләргә хуҗалык-көнкүреш хезмәте күрсәтүче хезмәткәрләрнең хезмәт хакы ставкаларының һәм административ-идарә итүче персоналның хезмәт хакы ставкаларының норматив нисбәте;

8 нче таблица нигезендә кабул ителә торган хуҗалык-көнкүреш хезмәте күрсәтүләре сатып алу нормаларын;

Чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджетын формалаштырганда кулланыла торган индекс-дефляторларны исәпкә алып, планнан алдагы елның 1 сентябренә хуҗалык-көнкүреш хезмәт күрсәтүләренең уртача базар бәясе.

**8 нче таблица**

**Гомуми белем бирү оешмалары каршында интернатта яшәүче тәрбияләнүчеләргә хуҗалык-көнкүреш хезмәте күрсәтү нормалары**

| Хезмәт күрсәтүнең атамасы | Норманы үлчәү бердәмлеге | Елына бер тәрбияләнүчегә норма |
|---|---|---|
| Мунча | юыну саны | 40 |

| | | |
|---|---|---|
| Кер юу буенча хезмәт күрсәтүләр | кг коры эчке кием | 50 |

2.17. Гомуми белем бирү оешмасы каршында интернатта яшәүче тәрбияләнүчеләргә хуҗалык-көнкүреш хезмәте күрсәтүне оештыру чыгымнары түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$R_{vbo} = FOT_{vbo} + \sum_{i_9=1}^{n_9} N_{i_{9bo}} \times C_{i_{9bo}},$$

биредә:

$FOT_{vbo}$ - тәрбияләнүчеләргә хуҗалык-көнкүреш хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы хезмәткәрләргә һәм административ-идарәче персоналга хезмәт хакы түләү фондына тәрбияләнүчеләргә хуҗалык-көнкүреш хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы хезмәткәрләргә һәм административ-идарәче персоналга исәпләнгән хезмәт хакы фонды;

$N_{i_{9bo}}$ - 2.16 пункты нигезендә кабул ителә торган тәрбияләнүчеләргә хуҗалык-көнкүрештә хезмәт күрсәтү хезмәтләрен2.16 пункты нигезендә кабул ителә торган сатып алу нормалары;

$C_{i_{9bo}}$ - тәрбияләнүчеләргә хуҗалык-көнкүреш хезмәте күрсәтү исемлегенә керә торган 2.16 пункты нигезендә кабул ителә торган хезмәт күрсәтүләрнең бәясе;

$n_9$ - тәрбияләнүчеләргә хуҗалык-көнкүреш хезмәт күрсәтү хезмәтләрен сатып алуның билгеләнгән нормалары исемлегенә туры килә торган, 2.16 пункты буенча, тәрбияләнүчеләргә хуҗалык-көнкүреш хезмәт күрсәтү хезмәтләре саны

$i_9$ - 2.16 пунктта каралганча тәрбиячеләргә хуҗалык-көнкүреш хезмәте күрсәтү атамасы.

2.18. Тәрбияләнүчеләргә хуҗалык-көнкүреш хезмәте күрсәтүнең бәясен исәпләү түбәндәге күрсәткечләрдән чыгып гамәлгә ашырыла:

тәрбияләнүчеләргә хуҗалык-көнкүреш хезмәте күрсәтүче хезмәткәрләр ставкалары саны, бер тәрбияләнүчегә - 0,12;

тәрбияләнүчеләргә хуҗалык-көнкүреш хезмәте күрсәтүне гамәлгә ашыручы хезмәткәрләре эш хакы ставкасы икенче квалификация разряды буенча тарифлаштырылган эшчеләрнең гомумтармак һөнәрләре буенча һөнәри квалификация төркемендәге «Эшчеләрнең беренче дәрәҗәдәге гомуми тармак һөнәрләре» квалификация төркеменең беренче квалификация дәрәҗәсенә каралган эшчеләр һөнәренә туры килә.

2.19. Административ-идарә персоналының хезмәте өчен түләү чыгымнары өлеше гомуми белем бирү оешмасы тәрбияләнүчеләренә хуҗалык-көнкүреш хезмәте күрсәтүче хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү фондының 12 проценты күләмендә билгеләнә.

2.20. Тәрбияләнүчеләргә хуҗалык-көнкүреш хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы хезмәткәрләргә һәм административ-идарәче персоналга хезмәт хакы

түләү фонды тәрбияләнүчеләргә хуҗалык-көнкүреш хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы хезмәткәрләргә һәм административ-идарәче персоналга хезмәт хакы түләү фондына түләүләр түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$FOT_{vbo} = FOT_{vbo_{осн}} + FOT_{vbo_{ауп}},$$

биредә:

$FOT_{vbo_{осн}}$ - тәрбияләнүчеләргә хуҗалык-көнкүреш хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы хезмәткәрләргә хезмәт хакы түләү фондына түләүләр белән тәрбияләнүчеләргә хуҗалык-көнкүреш хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы хезмәткәрләргә хезмәт хакы түләү фонды ;

$FOT_{vbo_{ауп}}$ - административ-идарә итү һәм уку-укыту-ярдәмче персоналның хезмәтенә түләү фонды һәм хезмәт өчен түләү фондына 2.19 пункты нигезендә кабул ителә торган административ-идарә һәм укыту-ярдәмче персоналның хезмәт хакы фондына түләүләр.

2.21. Тәрбияләнүчеләргә хуҗалык-көнкүреш хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы хезмәткәрләргә хезмәт хакы түләү фондына исәпләүләре белән, тәрбияләнүчеләргә хуҗалык-көнкүреш хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы хезмәткәрләргә хезмәт хакы түләү фонды түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$FOT_{vbo_{осн}} = n_{bo} \times b_{bo} \times e \times 12,$$

биредә:

$n_{bo}$ - тәрбияләнүчеләргә хуҗалык-көнкүреш хезмәте күрсәтүче хезмәткәрләрнең, 2.18 пункты нигезендә кабул ителә торган, ставкалар саны;

$b_{bo}$ - тәрбияләнүчеләргә хуҗалык-көнкүреш хезмәте күрсәтүче хезмәткәрләрнең 2.18 пункты нигезендә кабул ителә торган, хезмәт хакын түләүгә чыгымнар;

e - законнар нигезендә иминият кертемнәре күләме;

12 - елга айлар саны.

2.22. Тәрбияләнүчеләргә медицина хезмәте күрсәтүне оештыру чыгымнары хезмәт өчен түләүгә агымдагы чыгымнарны һәм медикаментлар һәм бәйләвеч чаралары сатып алуга чыгымнарны үз эченә ала.

2.23. Тәрбияләнүчеләргә медицина хезмәте күрсәтүне оештыру чыгымнары гомуми белем бирү оешмасының интернатлары өчен формалаштырыла. Гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернатта тәрбияләнүчеләргә медицина хезмәте күрсәтү тиешле сәламәтлек саклау учреждениесе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2.24. Балаларга медицина хезмәте күрсәтүне оештыру чыгымнары расланган нормативлар нигезендә түбәндәгеләр нигезендә билгеләнә:

тәрбияләнүчеләргә медицина хезмәте күрсәтү бәясе;

медицина хезмәткәрләре хезмәт хакы ставкаларының һәм административ-идарә персоналы хезмәт хакы ставкаларының норматив нисбәте;

медикаментлар һәм бәйләвеч чаралары сатып алу нормалары,9 нчы таблицада каралганча;

Чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджетын формалаштырганда кулланыла торган индекс-дефляторларны исәпкә алып, планнан алдагы елның 1 сентябренә медикаментлар һәм бәйләвеч чараларның уртача базар бәясе.

**9 нчы таблица**

**Гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатта тәрбияләнүчеләрне медикаментлар һәм бәйләвеч чаралары белән тәэмин итү нормалары**

| Медикаментларның һәм бәйләвеч чараларының аталышы | Үлчәү берәмлеге | Елына бер тәрбияләнүчегә норма |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Бактерицид лейкопластырь 6 х 10 | данә | 3 |
| Термометр (медицина) | данә | 3 |
| Стериль булмаган бинт 7 х 14 | данә | 1,9 |
| "Ревит" поливитаминнары № 50 | упаковка | 1,9 |
| 0,5 № 10 Анальгин | упаковка | 1,9 |
| Аспирин 0,5 № 10 | упаковка | 1,9 |
| Спиртлы нашатыр 10% - 40,0 | флакон | 3 |
| Активлаштырылган күмер 0,25 N 10 | упаковка | 3 |
| Спитртлы йод эремәсе 5% - 10,0 | флакон | 0,6 |
| Горчичниклар № 20 | упаковка | 35 |
| Хирургия мамыгы | кг | 0,3 |
| Калий перманганаты 3,0 | флакон | 0,6 |
| Димедрол 0,05 № 10 | упаковка | 1,12 |
| Парацетамол 0,2 № 10 | упаковка | 1,9 |
| Бриллиант яшел эремәсе 1% - 100,0 | флакон | 0,6 |
| Альбуцид эремәсе 30% - 5,0 | флакон | 2,3 |
| Бор спирты 3% - 10% | флакон | 1,9 |
| Ферроплекс (драже) № 100 | упаковка | 0,72 |
| Кальция глюконаты 0,5 № 10 | упаковка | 1,9 |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| Оксолин мазе 0,25 % - 10,0 | упаковка | 1,12 |
| Интерферон (ампулы) № 10 | ампул | 1,9 |
| Эритромицин мазе 10,0 | упаковка | 1,12 |
| Ампиокс 500 мең берәмлек | флакон | 14,6 |
| Панкреатин (таблеткалар) 250 мг № 10 | упаковка | 35 |
| Дибазол № 10 | упаковка | 1,9 |
| Бронхолитин сироп 125,0 | флакон | 1,9 |
| Нафтизин 0,1% - 10,0 | флакон | 1,9 |
| Вишневский мазе 100,0 | флакон | 0,6 |
| Ингалипт (аэрозоль) 30,0 | упаковка | 1,9 |
| Бисептол (таблетка) 480 мг № 20 | упаковка | 1,12 |
| Эритромицин (таблеткалар) 0,25 № 10 | упаковка | 1,12 |
| Валериана (таблетка) 0,1 г | упаковка | 0,4 |
| Новокаин 0,05% № 10 | ампул | 0,6 |
| Экалипт настойкасы 100,0 | флакон | 0,6 |
| Задитен (кетотифен), сироп 100,0 | флакон | 0,83 |
| Элеутерокок настойкасы 100,0 | флакон | 0,6 |
| Аскорбин кислотасы № 200 | упаковка | 1,6 |
| Шприцы | данә | 2,5 |
| Гигиена хатын-кыз пакеты № 10 | упаковка | 7 |
| Корвалол 20,0 | флакон | 0,2 |
| Кордиамин 20,0 | флакон | 0,2 |

2.25. Тәрбияләнүчеләргә медицина хезмәте күрсәтүне оештыру чыгымнары түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$R^{t}_{v_{mo}} = FOT^{t}_{v_{mo}} + \sum_{i_{10}=1}^{n_{10}} N_{i_{10} v_{mo}} \times C_{i_{10} v_{mo}} ,$$

биредә:

$FOT^{t}_{v_{mo}}$ - медицина хезмәткәрләренең һәм административ-идарәче персоналның хезмәт хакы фондына исәпләүләр белән медицина хезмәткәрләренең һәм административ - идарәче персоналның хезмәт хакы фонды ;

$N_{i_{10} v_{mo}}$ - 2.24 пункты нигезендә кабул ителә торганмедикаментлар һәм

бәйләвеч чаралары сатып алу нормалары;

$C_{i10_{vmo}}$ - 2.27 пункт нигезендә кабул ителә торган медикаментлар һәм бәйләвеч чаралары бәясе;

$n_{10}$ - тәрбияләнүчеләрне медикаментлар һәм бәйләвеч чаралары белән тәэмин итүнең билгеләнгән нормалары исемлегендә, 2.24 пункты нигезендә кабул ителә торган, медикаментлар һәм бәйләвеч чаралары саны ;

$i_{10}$ - тәрбияләнүчеләрне медикаментлар һәм бәйләвеч чаралары белән тәэмин итүнең билгеләнгән нормалары исемлегендә, 2.24 пункты нигезендә кабул ителә торган, медикаментлар һәм бәйләвеч чаралары атамалары;

2.26. Тәрбияләнүчеләргә медицина хезмәте күрсәтү буенча хезмәт күрсәтүнең бәясен исәпләү түбәндәге күрсәткечләрдән чыгып гамәлгә ашырыла:

интернаты булган гомуми белем бирү оешмасында бер тәрбияләнүчегә өлкән медицина персоналы ставкалары саны - 0,01;

интернаты булган гомуми белем бирү оешмасында бер тәрбияләнүчегә урта медицина персоналы ставкалары саны - 0,02;

өлкән медицина персоналының хезмәт хакы ставкалары сәламәтлек саклау хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү буенча дүрт разрядлы тариф челтәренең дүртенче разрядына туры килә;

урта медицина персоналының хезмәт хакы ставкалары сәламәтлек саклау хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү буенча дүрт разрядлы тариф челтәренең икенче разрядына туры килә.

2.27. Административ-идарә персоналының хезмәте өчен түләү чыгымнары өлеше гомуми белем бирү оешмасының медицина хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү фондының 12 проценты күләмендә билгеләнә.

2.28. Медицина хезмәткәрләренең һәм административ-идарәче персоналның хезмәт хакы фонды медицина хезмәткәрләренең һәм административ-идарәче персоналның хезмәт хакы фондына исәпләүләр белән түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$FOT^{t}_{vmo} = FOT^{t}_{vmo_{oc}} + FOT^{t}_{vmo_{ayп}},$$

биредә:

$FOT^{t}_{vmo_{oc}}$ - медицина хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү фондына исәпләүләр белән медицина хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү фонды;

$FOT^{t}_{vmo_{ayп}}$ - 2.27 пункты нигезендә кабул ителә торган административ-идарә итү һәм уку-укыту-ярдәмче персоналның хезмәтенә түләү фонды һәм хезмәт өчен түләү фондына административ-идарә һәм укыту-ярдәмче персоналның хезмәт хакы фондына түләүләр.

Медицина хезмәткәрләренең хезмәт хакы фонды медицина хезмәткәрләренең хезмәт хакы фондына исәпләүләр белән түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$FOT^{t}_{vmo_{oc}} = (n_{vmo_{st}} \times b_{mo_{st}}) + (n_{vmo_{sr}} \times b_{mo_{sr}}) \times$$
$$\times (1 + o_b \times r^t)) \times e \times 12,$$

биредә:

$n_{vmo_{st}}$ - 2.29 пункты нигезендә кабул ителә торган өлкән медицина персоналы ставкалары саны;

$b_{mo_{st}}$ - 2.26 пункты нигезендә кабул ителә торган өлкән медицина хезмәткәрләренең хезмәтен түләүгә чыгымнар;

$n_{vmo_{sr}}$ - 2.26 пункты нигезендә кабул ителә торган урта медицина персоналы ставкалары саны;

$b_{mo_{sr}}$ - 2.26 пункты нигезендә кабул ителә торган урта медицина хезмәткәрләренең хезмәтен түләүгә чыгымнар;

$o_b$ - сәламәтлек саклау хезмәткәрләренең хезмәт хакы буенча дүрт разрядлы тариф челтәренең беренче разрядлы тариф ставкасы (оклады) күләме;

$r^t$ - авыл җирендә эшләгән өчен белгечләргә компенсация характерындагы түләү күләме;

$12$ - елга айлар саны.

## Гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда балаларны тәрбияләп тоту өчен ата-ана түләвен формалаштыру һәм алу

### 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда балаларны тәрбияләп тоту өчен ата-ана түләвен формалаштыру һәм алу гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда балаларны тоту өчен ата-аналар түләүләрен формалаштыру, билгеләү, үзгәртү һәм алу механизмын билгели.

1.2. Гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда тәрбияләнүчеләрне (законлы вәкилләрне) матди карап торган өчен законнар нигезендә ата-ана түләве алынырга мөмкин.

1.3. Гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда тәрбияләнүчеләрне карап торган өчен ата-ана түләвен исәпләү һәм алу тәртибе гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнә.

1.4. Интернатта тәрбияләнүчеләрне карап тоту өчен ата-аналар түләвен билгеләгәндә исәпкә алынган чыгымнар исемлеге һәм күләме интернатны оештыручының норматив хокукый акты белән билгеләнгән интернатта тәрбияләнүчеләрне карап тотуга норматив чыгымнарга кертелгән чыгымнар исемлегенә һәм күләменә туры килә.

1.5. Интернатта тәрбияләнүчеләрне тотуга норматив чыгымнар күләме ел саен интернатны оештыручының норматив хокукый акты белән билгеләнә.

## 2. Гомуми белем бирү оешмалары каршында интернатларда тәрбияләнүчеләрне карап торкан өчен ата-ана түләвенең күләмен исәпләп чыгару тәртибе

2.1. Интернатта тәрбияләнүчеләрне карап тоту өчен ата-ана түләүләре айга бер тәрбияләнүчегә интернатта тәрбияләнүче гаилә әгъзасының уртача гомуми керемәнә һәм җан башына яшәү минимумы күләмәнә бәйле рәвештә билгеләнә

2.2. Интернатларда тәрбияләнүчеләрне карап торкан өчен ата-аналар түләве күләме интернатларда тәрбияләнүчеләрне карап тотуга норматив чыгымнарның түбәндәге күләмнәрендә билгеләнә:

8 процент - гаиләнең уртача җыелма кереме гаилә әгъзасына тулаем Татарстан Республикасы буенча типик гаилә әгъзасына билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән кимрәк булган гаиләләр өчен;

12 процент - гаилә әгъзасына уртача кереме Татарстан Республикасы буенча тулаем типик гаилә әгъзасына 1 дән алып 1,5 кә кадәр яшәү минимумы күләмен тәшкил иткән гаиләләр өчен;

15 процент - гаилә әгъзасына уртача кереме Татарстан Республикасы буенча тулаем типик гаилә әгъзасына 1,5 тән алып 3кә кадәр яшәү минимумы күләмен тәшкил иткән гаиләләр өчен;

50 процент - гаилә әгъзасына уртача кереме Татарстан Республикасы буенча тулаем типик гаилә әгъзасына билгеләнгән яшәү минимумының 3тән алып 4кә кадәр күләмен тәшкил иткән гаиләләр өчен;

100 процент - гаилә әгъзасына уртача кереме Татарстан Республикасы буенча тулаем алганда типик гаилә әгъзасына билгеләнгән яшәү минимумының 4 күләменнән артып киткән гаиләләр өчен.

2.3. Интернатларда тәрбияләнүчеләрне карап тоту өчен ата – аналар түләве медицина бәяләмәсе нигезендә сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалардан һәм ата-анасы икесе дә I яки II группа инвалид булган гаиләләрдән алынмый.

2.4. Интернатта тәрбияләнүчеләрне карап тоту өчен ата-ана түләүләре, тәрбияләнүче каникул чорында һәм авырган вакытта булмаган көннәр санынан чыгып, тәрбияләнүчеләрне туклану белән тәэмин итү чыгымнары күләме киметелергә тиеш. Интернатта тәрбияләнүчеләр башка нигезләр буенча булмаган очракта, интернатларда балаларны караган өчен ата-аналар түләве үзгәрергә тиеш түгел. Тәрбияләнүчеләрне туклану белән тәэмин итү чыгымнары күләме тәрбияләнүчеләрне интернатларда карап тотуга норматив чыгымнарга кертелә торган азык-төлек сатып алу чыгымнары күләмәнә тигез дип кабул ителә.

2.5. Тәрбияләнүче интернаттан сәбәпсез чыгып киткән очракта, тәрбияләнүчене интернатта карап торкан өчен агымдагы ай өчен ата-ана түләве кире кайтарылмый.

2.6. Тәрбияләнүчене интернаттан башка гомуми белем бирү оешмасына күчергәндә, ата-ана түләве интернатта тәрбияләнүчене карап торкан өчен

агымдагы айның калган көне өчен тәрбиячене күчергәннән соң кайтарылырга тиеш.

2.7. Гаилә әгъзасына уртача гомуми керем 2003 елның 5 апрелендәге «Гаиләнең уртача җан башына керемнәрен исәпкә алу һәм аларны аз керемле дип тану һәм аларга дәүләт социаль ярдәме күрсәтү өчен ялгыз яшәүче гражданның керемен исәпләү тәртибе турында»гы 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә билгеләнә.

2.8. Бер кеше башына исәпләнгән яшәү минимумы күләме тиешле вакытка Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый акты белән билгеләнгән күләмдә кабул ителә.

## 3. Интернатларда тәрбияләнүчеләрне карап торткан өчен ата-ана түләвенең күләмен билгеләү һәм үзгәртү тәртибе

3.1. Интернатта тәрбияләнүчеләрне карап тоту өчен ата-ана түләвенең күләмен һәр тәрбияләнүче өчен интернат җитәкчесе квартал саен, алдагы кварталның соңгы аеның 20 нче көненә кадәр, алдагы кварталның барлык гаилә әгъзаларының керемнәрен раслый торган документлар нигезендә билгели.

3.2. Ата-аналар түләүенең күләмен билгеләү өчен, интернатта тәрбияләнүчеләре булган ата-аналар (законлы вәкилләр) интернат җитәкчесенә уку елына кадәрге айның 20 числосына кадәр гаилә әгъзасына уртача гомуми керемне билгеләү өчен кирәкле белешмәләр белән документлар тапшыралар. Гаилә әгъзасына җыелма керемне билгеләү өчен нигез булган документлар интернатта тәрбияләнүченең шәхси эш папкасында саклана.

3.3. Интернатта тәрбияләнүчеләрнең ата-аналары (законлы вәкилләре) гаиләнең уртача гомуми керемен билгеләү өчен кирәкле белешмәләрне 3.2 пунктта билгеләнгән вакытта тапшырмаган очракта, интернатта тәрбияләнүчеләрне карап тоту өчен ата-аналар түләве күләме интернатта тәрбияләнүчеләрне карап тоту өчен норматив чыгымнарның 100 проценты күләмендә билгеләнә.

3.4. Уку елы дәвамында гаилә әгъзасының уртача гомуми керемен билгеләү өчен нигез булган белешмәләр үзгәргәндә, тәрбияләнүченең ата-аналары (законлы вәкилләре) гаилә әгъзасының уртача гомуми керемен билгеләү өчен нигез булган белешмәләр үзгәргәннән соң бер ай эчендә интернатка төгәлләнгән белешмәләр һәм документлар тапшырырга тиеш.

3.5. 3.4 пунктында күрсәтелгән белешмәләр үзгәргәндә, интернатта тәрбияләнүчеләрне карап торткан өчен ата-аналар түләве күләме тәрбияләнүченең ата-анасы (законлы вәкилләре) тарафыннан интернатка тапшырылган айдан соң килүче айның беренче числосыннан гаилә әгъзасына уртача җыелма керемне билгеләү өчен нигез булып торучы үзгәртелгән белешмәләрне тапшырырга тиеш.

3.6. Интернатларда балаларны карап тоту өчен ата-аналар түләве хисабына каплана торган азык-төлек продуктлары бәясе интернатта балаларны карап торткан өчен ата-аналар түләвеннән бүлеп бирелергә тиеш.

3.7. Интернатларда тәрбияләнүчеләрне карап тоту өчен ата-аналар түләве күләме, әгәр дә тәрбияләнүчеләрне интернатларда карап тоту өчен норматив чыгымнар күләме билгеләнгән тәртиптә үзгәрсә, гамәлдә булган чорда вакытыннан алда яңадан каралырга тиеш.

**4. Интернатта тәрбияләнүчеләрне карап тоткан өчен ата-ана түләвен алу тәртибе**

4.1.Интернатта балаларны карап тоту өчен ата-аналар түләве ай саен, агымдагы ай өчен түләнә торган айның 10 ысыннан да соңга калмыйча кертелә.

4.2. Опекада (попечительлектә) торучы тәрбияләнүчеләрне интернатта тоткан өчен ата-ана түләве әлеге балаларга билгеләнгән пенсияләрдән, дәүләт пособиеләреннән һәм алиментлардан алына.

4.3. Ятим балаларны һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар тулысынча дәүләт тарафыннан тәэмин итүгә керткәндә, закон нигезендә бу балаларга билгеләнгән пенсияләр һәм пособиеләр , 2.2 пунктында каралган күләмдә, интернатта тәрбияләнүчеләрне карап тоткан өчен ата-аналар түләве исәбенә күчерелә.

4.4. 4.3 пунктында күрсәтелгән балалар булмаган очракта, интернатта каникуллар чорында билгеләнгән пенсия яисә пособие тулы күләмдә түләнә.

4.5. Әгәр дә тәрбияләнүчеләрне интернатта карап тоткан өчен ата-ана түләве билгеләнгән вакыттан соң ике атна эчендә түләнмәсә, күрсәтелгән сумма закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә түләнә.

4.6. Интернатта тәрбияләнүчеләрне карап тоткан өчен ата-аналар түләвенең артык кертелгән өлеше, аны керткән көннән алып, бер ел узганчы, интернат җитәкчесенә гариза биргән очракта , кире кайтарыла.

4.7. Интернатта тәрбияләнүчеләрне карап тоткан өчен артык булган ата-ана түләвен кире кайтару, интернат җитәкчесенә гариза биргән көннән соң ике атна эчендә башкарыла.

**Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларын финанс белән тәэмин итү күләмен**
**ИСӘПЛӘҮ ТӘРТИБЕ**

**1. Гомуми нигезләмәләр**

1.1. Әлеге Тәртип Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмасын финанс белән тәэмин итү күләмен исәпләү механизмын билгели.

**2. Гомуми белем бирү оешмаларын финанс белән тәэмин итү күләмен исәпләү тәртибе**

2.1. Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларын финанс белән тәэмин итү күләме үз эченә түбәндәгеләрне ала:

мәктәпкәчә белем бирүнең , башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандартын (төп гомуми белем бирү программаларын), өстәмә гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга, укучыларның озайтылган көн төркемендә булуларын оештыруга финанс тәэмин итү күләме;

гомуми белем бирү оешмасы мөлкәтен карап тотуга (эксплуатацияләүгә) финанс белән тәэмин итү күләме;

гомуми белем бирү оешмасының мәктәпкәчә бүлегендә тәрбияләнүчеләрне карап тотуга финанс белән тәэмин итү күләме;

гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернат мөлкәтен карап тотуга (эксплуатацияләүгә) финанс белән тәэмин итү күләме;

гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернатта тәрбияләнүчеләрне карап тотуга финанс белән тәэмин итү күләме.

2.2. Гомуми белем бирү оешмасын финанс белән тәэмин итү күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$FOSC^{t} = FOSC^{t}_{fgos} + FOSC^{t}_{si} + FOSC^{t}_{svd} + FOSC^{t}_{sii} + FOSC^{t}_{svi},$$

биредә:

$FOSC^{t}$ - Зеленодольск муниципаль районында гомуми белем бирү оешмасын финанс белән тәэмин итү күләме;

$FOSC^{t}_{fgos}$- мәктәпкәчә белем бирүнең , башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандартын (төп гомуми белем бирү программаларын), өстәмә гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга, укучыларның озайтылган көн төркемендә булуларын оештыруга финанс тәэмин итү күләме;

$FOSC^{t}_{si}$ - гомуми белем бирү оешмасы мөлкәтен карап тотуга (эксплуатацияләүгә) финанс белән тәэмин итү күләме;

$FOSC^{t}_{svd}$ - Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» 2017 елның 25 июлендәге 2029 номерлы карары белән расланган гомуми белем бирү оешмасының мәктәпкәчә бүлегендә тәрбияләнүчеләрне матди яктан тәэмин итү күләме Зеленодольск муниципаль районының мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында тәрбияләнүчеләрне карау һәм тәрбияләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнар исәпләвенә нигезләнеп билгеләнә.

$FOSC^{t}_{sii}$ - гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернат мөлкәтен карап тотуга (эксплуатацияләүгә) финанс белән тәэмин итү күләме;

$FOSC^{t}_{svi}$ - гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернатта тәрбияләнүчеләрне карап тотуга финанс белән тәэмин итү күләме.

2.3. мәктәпкәчә белем бирүнең , башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандартын (төп гомуми

белем бирү программаларын), өстәмә гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга, укучыларның озайтылган көн төркемендә булуларын оештыруга финанс тәэмин итү күләме;

$$FOSC_{fgos}^{t} = \sum_{p=1}^{m} (j_{ip} \times N_{sdpf_{gos}}^{t} + 0{,}2 \times (c^{fact} - c^{norm}) \times N_{sdpf_{gos}}^{t} + 0{,}5 \times (\kappa^{norm} - \kappa^{fact}) \times$$

$$\times N_{sdpf_{gos}}^{t} + N_{ddo}^{t} \times j_{ddo} + j_{i_{gpd}} \times N_{gpd}^{t} + FOSC_{fgos_{doy}}^{t} + N_{sdpf_{ink}}^{t} \times K_{k}),$$

биредә:

$N_{sdpf_{gos}}^{t}$- гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнар;

$j_{ip}$ - i гомуми белем бирү оешмасында белем алучыларның (аз комплектлы мәктәпләр өчен сыйныф-комплектлар) саны;

$c^{norm}$- саннары норматив тулылыктан югарырак булган сыйныфларда укучыларның норматив саны;

$c^{fact}$ - саны норматив тулылыктан югарырак булган сыйныфларда укучылар саны;

$к^{norm}$- саны норматив тулылыктан түбәнрәк булган сыйныфларда укучыларның норматив саны;

$к^{fact}$ - саны норматив тулылыктан түбәнрәк булган сыйныфларда белем алучылар саны;

$N_{ddo}^{t}$ - гомуми белем бирү оешмаларында өстәмә гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнар;

$j_{ddo}$ - i гомуми белем бирү оешмасының өстәмә белем бирүнең барлык дәрәҗәләрендә белем алучылар саны;

$N_{gpd}^{t}$- гомуми белем бирү оешмаларында озынайтылган көн төркемен финанслау нормативы;

$j_{i_{gpd}}$ - гомуми белем бирү оешмасының укучылары саны;

$N_{sdpf_{ink}}^{t}$ - гомуми белем бирү оешмаларында инклюзив белем бирү оештыру аша сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән һәм акыл ягыннан артта калган укучылар өчен башлангыч гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнар;

$K_{k}$ - инклюзив белем бирү гамәлгә ашырыла торган гомуми белем бирү оешмаларында сыйнфый-комплектлар саны;

0,2 - сыйныфларда укучылар саны норматив тулылыктан артык булган оешмалар өчен нормативтан өлеш;

0,5 - сыйныфларда белем алучыларның саны норматив тулылыктан түбәнрәк булган оешмалар өчен нормативтан өлеш;

t – гомуми белем бирү оешмасының территориаль урнашу урыны;

$p$ - мәгариф профиле;

$m$ - профильләр саны;

$FOSC^{t}_{fgos_{doy}}$ - Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск муниципаль районының мәктәпкәчә мәгариф оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» 2017 елның 25 июлендәге 2029 номерлы карары белән расланган Зеленодольск муниципаль районының мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен исәпләп чыгару буенча финанс чыгымнары нормативларын исәпләү нигезендә билгеләнә торган мәктәпкәчә белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандартын гамәлгә ашыруга финанс белән тәэмин итү күләме.

2.4. Гомуми белем бирү оешмасы мөлкәтен карап тотуга (эксплуатацияләүгә) финанс белән тәэмин итү күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$FOSC^{t}_{si} = BNSI^{t}_{vn} \times KNSI^{t}_{ivf} \times Sq_{i},$$

биредә:

$BNSI^{t}_{vn}$ - гомуми белем бирү оешмасы мөлкәтен карап тотуга (эксплуатацияләүгә) база нормативы;

$KNSI^{t}_{ivf}$ - i-гомуми белем бирү оешмасының мөлкәтен карап тотуга (эксплуатацияләүгә) база нормативына карата төзәтмә коэффициенты;

$Sq_{i}$ - гомуми белем бирү оешмасының мәйданы белән факттагы тәэмин ителеш.

2.5. Гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернат мөлкәтен карап тотуга (эксплуатацияләүгә) финанс белән тәэмин итү күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$FOSC^{t}_{sii} = BNSI^{t}_{v} \times KNSI^{t}_{iv} \times Sq_{ii},$$

биредә:

$BNSI^{t}_{v}$ - гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернат мөлкәтен карап тотуга (эксплуатацияләүгә) база нормативы;

$KNSI^{t}_{iv}$ - i гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернат мөлкәтен карап тотуга (эксплуатацияләүгә) база нормативына төзәтмәләр коэффициенты;

$Sq_{ii}$ - гомуми белем бирү оешмасы каршындагы (бер тәрбияләнүчегә) интернат мәйданының факттагы тәэмин ителеше.

2.6. Гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернатта тәрбияләнүчеләрне карап тотуга тәэмин итү күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$FOSC^{t}_{svi} = \sum_{p=1}^{m} (NSV^{t}_{v} \times j_{v}) - RP_{insv},$$

биредә:

$NSV_v^t$ - гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернатта тәрбияләнүчеләрне карап тотуга норматив чыгымнар, Татарстан Республикасы законнары нигезендә туклануга субсидияләрне дә кертеп;

$j_v$ - гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернатта тәрбияләнүчеләр саны;

$RP_{insv}$ - гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернатта тәрбияләнүчеләрне карап тоткан өчен ата-аналар түләвеннән кергән финанс чараларының гомуми күләме.